DOI: 10.26907/2311-2042-2022-18-1-188-198

# COMPOSER MANSUR MOZAFFAROV: ORIGINAL STYLE OF CREATIVE WORK

**Klara Sabirovna Tazieva,**
mileuscha@mail.ru.



**Muzafarov Mansur Akhmetovich** (03.06.1901[1] – 11.21.1966) was a composer, teacher, Honored Artist of the TASSR (1950) and People's Artist of the TASSR (1964). He was the first Tatar composer with a higher specialized education. He began his creative activity as a member of national instrumental ensembles. In 1931, he graduated from the Ethnographic Department of the Moscow Conservatory. In 1938-1939, he studied at the Tatar Opera Studio of the Moscow Conservatory. From 1945, he taught at the Kazan Conservatory (in 1949-1961 he was the head of the Composition Department). Over the years, he conducted creative work on the radio and in the Tatar

**Мозаффаров Мансур Әхмәт улы** (06.03.1901[2] – 21.11.1966), композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1950), ТАССРның халык артисты (1964). Югары махсус белемле беренче татар композиторы. Иҗади эшчәнлеген милли инструменталь ансамбльләр катнашучысы буларак башлый. 1931 елда Мәскәү консерваториясенең этнографик бүлеген тәмамлый. 1938-1939 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый. 1945 елдан Казан консерваториясендә укыта (1949–1961 елларда композиция кафедрасы мөдире). Төрле елларда радиода, Татар опера һәм балет театрында иҗат

**Музафаров Мансур Ахметович** (06.03.1901[3] – 21.11.1966), композитор, педагог, засл. деятель искусств ТАССР (1950), народный артист ТАССР (1964). Первый татарский композитор с высшим специальным образованием. Творческую деятельность начал в качестве участника национальных инструментальных ансамблей. В 1931 г. окончил этнографическое отделение Московской консерватории. В 1938–1939 гг. обучался в Татарской оперной студии при Московской консерватории. С 1945 г. преподавал в Казанской консерватории (в 1949–1961 гг. зав. кафедрой композиции). В разные годы вел творческую работу на радио, в

[1] In the course of our research work, we detected an error in the dating of the composer's birthday. Based on the available archival information, we consider it necessary to make the necessary adjustments. The mistake was made due to the fact that the anniversary of M. Muzaffarov was celebrated in 1962 instead of 1961, the event was actually postponed for a year, because the organizers did not have enough time to prepare it.

[2] Тикшеренү эшләре барышында без композиторның туган көне датировкасында хата таптык. Табылган архив белешмәсе нигезендә тиешле төзәтмәләр кертүне дөрес дип саныйбыз. Бу хата М.Мозаффаровның 1961 елда булган юбилеен 1962 елда билгеләп үтелүе аркасында килеп чыккан. Юбилейны әзерләргә вакыт җитмәгәнлектән аны икенче елга күчерергә булганнар.

[3] В процессе нашей исследовательской работы мы выявили ошибку в датировке дня рождения композитора. На основании имеющейся архивной справки считаем необходимым внести коррективы. Ошибка была допущена из-за того, что юбилей М. Музафарова отмечался вместо 1961 г. в 1962 г. Мероприятие на деле было перенесено на год, так как у организаторов не хватило времени для его подготовки.

Opera and Ballet Theatre.

Muzafarov’s legacy as a composer is extensive: from arrangement of folk tunes, original songs, romance songs to large-scale works in the genres of opera, symphonic poem and instrumental concert.

The name of Mansur Muzafarov is associated with the Children's Music School No. 18, located in the Kirovsky district of Kazan. This school hosts the Republican Competition “Mozaffarov kichlərе” (“Muzaffar Evenings”).

A memorial plaque to the composer was installed in Kazan at 5 Nikolaev Street.

эшчәнлеге алып бара. М.Мозаффаровның композиторлык мирасы зур: фольклор көйләре, оригиналь җырлар, җыр-романслардан алып, опера, симфоник поэма, инструменталь концерт жанрларында зур күләмле әсәрләр бар. Мансур Мозаффаров исемен Казан шәһәренең Киров районында урнашкан 18 нче балалар музыка мәктәбе йөртә. Мәктәп базасында «Мозаффаров кичләре» республика бәйгесе уздырыла. Композиторга истәлекле такта Казанда Николаев урамының 5 йортына куелган.

Татарском театре оперы и балета.

Композиторское наследие Музафарова обширно: от обработок фольклорных напевов, оригинальных песен, песен-романсов до масштабных произведений в жанрах оперы, симфонической поэмы, инструментального концерта.

Имя Мансура Музафарова носит Детская музыкальная школа № 18, расположенная в Кировском районе города Казани. На базе школы проводится Республиканский конкурс «Мозаффаров кичләре» («Музафаровские вечера»).

Памятная доска композитору установлена в Казани на ул. Николаева, д. 5.

The work of Mansur Muzafarov, a representative of the older generation of Tatar composers, has been a remarkable phenomenon in Tatar professional music since his birth and the beginning of his professional career ([1], [2], [3], [4], [5], [6]). The composer’s worldview was shaped during the period of a strong rise in the national self-consciousness of the Tatar people during the years of the First Russian Revolution. From early childhood, the son of the famous Tatar poetess rapidly developed, surrounded by prominent figures of Tatar national literature and art, such as Gabdulla Tukay, Galimzyan Ibragimov and Salih Saydashev. He devoted his whole life to music, creativity and education of young Tatar musicians.

Throughout his career, M. Muzafarov consciously relied on the principles of realism and greatly contributed to the establishment of the spirit of nationality, internationalism and democracy, fidelity to the truth of life and deep humanity in the young national art.

Like other artists, Muzafarov had his own range of images. In most cases, this was a lyrical hero, who was in love with the surrounding life and glorified the beauty of the world. Often, the image of a poet was his protagonist, depicted both as a historical figure and a symbol of art, personifying folk thought and honor. In this sense, Muzafarov’s protagonist became the first example of interpretation of the image of the poet in Tatar music (the symphonic poem “In Memory of Gabdulla Tukay”) and his role in history.

Muzafarov’s creativity is characterised by the desire to see light in life, to find the ideal. It is more important for him to affirmrather than to deny, to describe internal contradictions and people who are more purposeful than angry, who can find ways leading to goodness and justice. In this respect, he is close to the Russian classics Glinka, Borodin and Rimskiy-Korsakov.

The characteristic feature of Muzafarov’s talent is his search for the lyrical aspects of his nation’s artistic thinking. This is due to the emotional and psychological nature of the composer himself, with his incredible modesty, amazing humanity, deep love for his nation, as well as with a rich musical talent as a composer and his ability to convey an extraordinary variety of emotions through music.

It is noteworthy that the lyrical trend that distinguishes Muzafarov from other Tatar composers remained unchanged throughout his creative work, which changed and enriched due to the penetration of epic and dramatic mobile qualities into his music, strengthening generalized philosophical principles in the themes of his works.

Muzafarov’s creative heritage is distinguished by a variety of genres. His works contributed to the genre enrichment of Tatar professional music as he was the first in Tatarstan to compose in multiple genres.

The works of the composer in the field of symphonic music are of particular importance, especially in the genre of the program poem. He enjoyed great success, raised an important topic in the history of Tatar progressive thought, such as the theme of the great Tatar poet Gabdulla Tukay (his symphonic poem “In Memory of Gabdulla Tukay”). The fact that he raised the theme of the fiery revolutionary Mullanur Vakhitov (“In

Memory of Mullanur Vakhitov") indicates that the composer turned to events that were of interest to the broad masses of the people. The works of Mansur Muzafarov show his high professional skills and a great talent of the real artist. He initiated the genre of program-lyrical-dramatic symphonic poems in Tatar music.

Mansur Muzafarov became one of the founders of the national symphony. Among his works are "Overture on Tatar Folk Tunes" (1932), "Symphony in E Minor" (1944), "Overture on Folk Tunes" (1951) and "Sinfonietta in Three Parts" (1954). Despite the fact that he did not reach classical heights in this area, his symphony, for the first time among Tatar works, reached a wider audience and was of great assistance to novice composers, such as A. Klyucharev, A. Valiullin and A. Monasyipov.

M. Muzafarov also became the first among national composers to master the genre of violin concerts. In this genre, he managed to create works that are distinguished by their melodic beauty, national color and inexhaustible lyrical flow, such as "Violin and Concerto for Orchestra No. 1" (1959), "Violin and Concerto for Orchestra No. 2" (1962).

As early as at the first stages of the formation of Mansur Muzafarov's symphonic style, its main feature could be clearly defined – the inextricable link between instrumental music and folk songwriting. Starting with a direct quotation of Tatar songs, some of their motifs and features, and applying his natural keys, intonation patterns and flexible plastics, Muzaffarov found his original themes similar to folk music.

In certain works, folk melodies often freely coexist with the melodies born of the composer's imagination. Just as melodic chants are formed by different variations of the same intonation, Mozaffarov's symphonic themes gradually grow from melodic elements that are similar to each other. The development of the theme in his arrangements is also determined by the undulating movement. It was in his mature works that the composer achieved generalization of the elements of the folk song language in a new way. His best works evidence this.

The formation of Tatar symphonic music was strongly influenced by other nationalities, in particular, Russian national culture. The masterful combination of new melodies and rhythms, interesting dramatic techniques with a national element brought new fresh trends into Muzafarov's work.

It should be noted that Muzafarov's symphonic works are associated with other genres, in particular with opera. The mastery of arranging melodies developed at the time of his careful work on opera recitatives. It was the work on the opera that helped him achieve the vivid imagery of instrumental thematics. The opposition of instrumental thematics and the song-vocal trend in Muzafarov's work stem from opera dramaturgy too.

Owing to the constant interaction of song and instrumental genres, the blending of national and classical cultures, Mansur Muzafarov achieved significant success in creating a new symphonic art in Tatar music.

Turning to the opera genre, Mansur Muzafarov chose the plots that were familiar and well-liked by a wide range of people. The composer used the intonational richness of popular folk songs that helped him reveal their content. This can be exemplified by his first opera "Galiabanu". In the national republics, where opera art was just beginning to develop, the practice of quoting folk melody can only be traced from a historical point of view. At certain stages of opera formation, this method had the right to exist. Moreover, it was necessary for the composer to attract different groups of the population to a new opera culture. This historical process was observed in Tatarstan, where the art of opera appeared only in Soviet times. In another opera "Zulkhabira", M. Muzafarov abandoned the idea of quoting folklore, reaching new heights in summarizing the elements of his people's musical language. Unlike "Galiabanu", this opera is based not on a song, but on a bayt. The bayt is a special genre of Tatar folklore, which involves a dramatic development of the storyline and requires new means of description. The combination of musical and poetic ways of the bayt genre with opera specifics was M. Muzafarov's new accomplishment. The transformation of a national feature into a high-quality, truly theatrical and musical vocabulary was a new stage in the development of national opera forms. Mansur Muzafarov's work proves it.

Muzafarov's musical and theatrical works expanded the genre palette of Tatar opera. His name is associated with the emergence of a lyrical-everyday opera in Tatar music.

The name of Muzafarov is also inseparable from the history of the Tatar song art development. Together with Salih Saidashev, Alexander Klyucharev, Dzhaudat Fayzi and Zakhid Khabibullin he initiated the creation of new Tatar

Soviet songs. Like many composers of the republic, he expressed in music his attitude to all significant events of that time. The emotional world of Muzafarov's music conveyed the devoted love of his contemporaries for their Motherland and their people, a sense of pride in their great deeds. In Muzafarov's songs, the listener is attracted by simplicity, sincerity and obvious emotionality. In his best songs, each phrase is perceived as the inner experience of each performer, it sounds amazingly fresh, uniquely beautiful.

The thematic range of the composer's songs is very wide (Motherland, his contemporaries, songs about pure love and funny songs); in them, the lyrical comonent occupies the main place, the composer makes an attempt to lyrically interpret even non-lyrical topics. The reason for this is Muzafarov himself, a lyrical composer. Even ordinary things he presents from an emotional and personal point of view, usually considering the feelings and experiences that are close to the masses.

The composer's intonation changes are clearly manifested in the genre of his songs. For example, each period of his creative work has its own descriptive means: the songs of the 1930s are characterized by bright and joyful cheerfulness, their similarity to folk tunes. In his post-war works, a tendency to harmonious lyricism is clearly expressed, while the works of the 1950s and early 1960s are both of lyrical and philosophical in nature, they are distinguished by the strengthening of individual style, the search for new intonations.

In a song, the main means of description is the melody. The bright, figurative accuracy of melodies contributed to the popularization of Muzafarov's songs. His melodies are similar to folk ones without copying "from others", i.e. "quoting" them; folk melodies are so subtly transmitted that they sound like new (original) melodies. Let us recall the words of B. V. Asafiev about the work of Glinka: "It is important not to copy the elements of the folk musical language, but, by generalizing these elements, to raise the musical consciousness to a new level". These words can also be referred to Mozafarov. They reflect his tireless work in collecting and arranging samples of folk vocal art, his deep penetration into the spirit and essence of folk melodies. But Muzafarov's work has its own self-created face and its own characteristic features: emotional intensity, depth of thought and melodies that radiate an unstoppable flame of feelings. In the best examples of his work, the melody spills freely and widely into a vast range, and the direction of growth expands like rings on water. The significance of the initial broad intonation is great in them (this is often achieved through a sexta, sometimes through a septima interval, in many cases it is due to a double interval). And in cheerful tunes such a significance of the initial intonation is associated with narrower intervals – a tertia, a quarta (for example, "A Postman's Song", "A Handkerchief"). No matter how wide and free the melodic images of Muzafarov's songs are, they always rely on the pentatonic scale inherent in folk melody. That is why they are easily assimilated, quickly perceived, despite all the intonation novelty, complexity and originality.

Another feature in the intonation development of Muzafarov's melody is the combinations inherent in Tatar folklore (the main tone is surrounded by neighboring sounds, forming a kind of "fellowship"). In the works of Muzafarov, there is a combination of closed intervals (secunda, tertia) and forming tones (quarta, quinta, sexta) ("The Quiet Garden", "The City Girl", "Climbing the Ural Mountains"). This approach adds a special fullness, stability and objectivity to the composer's lyrical melodies. His heroic-solemn songs are characterized by purposefulness due to the gradually growing tension flow (the song "Motherland").

Mansur Muzafarov made a great contribution to the development of Tatar folk songs. He enriched vocal works with new images and new types of genres. According to the musicologist A. Sohor, in the vocal music of the 1960s, there was a process of convergence of different genres with their active penetration into each other. Their boundaries were changing and composers searched for new genre types. Keeping pace with the requirements of that time, Mansur Muzafarov found a synthesized genre of a combined song-romance type.

His detailed work on the Tatar musical folklore, helped the composer achieve a high professional level and gain ideological and aesthetic maturity. Probably, the main feature of his style should be called national specificity. Muzafarov was one of the creators of the history of Tatar national music as he was one of the founders of the national musical language. It was folk songs that influenced the formation of the composer's style and established the predominance of certain artistic techniques in his work. Muzafarov's creative path began with his deep assimilation of folk songwriting. Mansur Muzafarov's creative arrangement of hundreds of Tatar folk songs proves that the composer tirelessly looked for the original folk qualities of Tatar music. He became one of those who

founded the genre of artistic arrangement of folk works. The composer's continuous work in this area led to real results: making his musical language more understandable to the people, summarizing the valuable elements of the Tatar musical culture and revealing his own independent style. The great merit of Mansur Muzafarov is collecting and publishing Tatar musical folklore.

The methods of folk art are of particular importance in the development of the material. But this does not mean a direct use of this method, it is rather a thoughtful processing through the prism of "personal self". Muzafarov's instrumental themes are an example of this, as this was how he worked. At the same time, the composer often used the techniques typical of classical music, regularly employing polyphonic methods, symphonizing the musical canvas and raising Tatar music to a higher quality level.

Mansur Muzafarov did a lot to develop the national musical language. He created his own, original style, which, in turn, contributed to the enrichment of all national music. His findings in the field of harmony and texture are invaluable. The tasks he set for consolidating harmony with the pentatonic scale were successfully solved, he found a theme that could be transferred to the symphony.

To designate the place that M. Muzafarov held in the process of the Tatarstan professional music development, we should also name those great masters who created music alongside him. First of all, his friend and colleague Salih Saidashev; then, composers Alexander Klyucharev, Nazip Zhiganov, Farit Yarullin, Zahid Khabibullin and Jaudat Faizi. Their creative work was closely related to folk art, to major topics. Still, each of them is extremely unique in their concrete expression. All of them had a great influence on the development of Tatar musical art.

Composers of the younger generation carefully study Muzafarov's oeuvre and continue his traditions in their works. This is mainly true of the lyrical realm of music. Like Muzafarov, their lyrical images attract our attention with their natural sound of the melodic development, the free flow of musical thinking. The lyrical tune characterizes the works of A. Monasypov and R. Enikeev, but at a new stage, in completely different conditions. We feel the influence of Muzafarov's song traditions in the works of R. Enikeev, A. Monasypov, I. Yakupov and R. Yakhin in strengthening their individual nature, its promotion to the fore. M. Yarullin and R. Bilyalov are working in the genre of creative arrangement. Moreover, like Mozafarov, R. Bilyalov has composed entire instrumental cycles based on folk songs. The symphonic poems by F. Akhmetov and A. Monasypov enriched the genre that Muzafarov had worked on in his time. Their one-part program works were dedicated to their contemporaries –poet Musa Jalil and composer Farid Yarullin. The features, similar to Muzafarov's lyric-dramatic symphonism, are also observed in chamber works of Tatar composers, in particular, in the second sonata by Renat Enikeev, dedicated to the memory of revolutionary Khusain Yamashev. In fact, it is a piano poem. Muzafarov's opera works aroused interest in lyrical and dramatic images which appear in the works of H. Valiullin, R. Gubaidullin and B. Mulekov.

On February 9, 2022, the grand opening of the Miras Tatar Music Festival took place at the Salikh Saidashev State Grand Concert Hall. The program of the first evening was dedicated to the 120$^{th}$ anniversary of Mansur Muzafarov. It was the first performance of an overture on Tatar themes, created in 1938 in the initial period of the composer's work. It is based on two Tatar folk songs: "The Son-in-Law" and "A Cuckoo". It was composer Ilyas Kamal who first performed the work, restored from the manuscripts, which were preserved in the composer's archive. The State Orchestra of Tatarstan also performed "Overture on a Theme in D" (1932) and a symphonic poem in memory of Mullanur Vakhitov. Of particular interest to the audience were such excerpts from the opera "Galiyabanu" as the Introduction, the aria of Galiabanu, the Dance, Badri's song and the Duet. The soloists were Ilyusa Khuzina and Ruslan Zakirov. Ilyas Kamal performed "The Melody" on the cello, accompanied by the orchestra (orchestrated by A. Luppov). The people were fascinated by the composer's song work. I. Khuzina sang the song "While Picking Berries", written to the verses of Musa Jalil. Singer Almas Khusainov sang "Motherland", written to the verses of Munir Mazunov. The amazing beauty and harmony of the melody, imbued with a subtle interpretation of the orchestra and the performance of the talented tenor A. Khusainov were highly appreciated by the audience. The event ended with an exceptionally beautiful and emotional concert. Among the participants was Dina Khisanbeyeva, a teacher of the Violin Department of the Kazan Conservatory, a laureate of All-Russian and international competitions. [7].

All of the above indicates the enormous role that Mansur Muzafarov played in the formation and development of Tatar professional musical art.

**References**

1. *Bashka berni də kirəkmi : f.-popul.ocherk, khatirələr, fotorəs* (2002) [Nothing Else Is Needed: A Popular-Science Essay, Memories, Photos]. Təz. K. S. Taҗieva; Tatar. G. N. Əkhmətҗanov tərҗ. 192 p. Kazan, Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)
2. Dulat-Aleev, V. (2007). *Mansur Muzafarov* [Mansur Muzafarov]. Dulat-Aleev V. Tatarskaya muzykal'naya literatura. Pp. 167–180. Kazan'. (In Russian)
3. Iskhakova-Vamba, R. A. (2006). *M. A. Muzafarov* [M. Muzafarov]. Iskhakova-Vamba R.A. Fol'klor i kompozitor (na materiale tatarskoi muzyki): ocherki. Pp. 44–58. Kazan', Shkola. (In Russian)
4. Nigmedzyanov, M. (1986). *Muzafarov Mansur* [Muzafarov Mansur]. Kompozitory i muzykovedy Sovetskogo Tatarstana. Pp. 106–113. Kazan'. (In Russian)
5. Salitova, F. Sh. (2008). *Muzafarov Mansur Akhmetovich* [Muzafarov Mansur Akhmetovich]. Tatarskaya ehntsiklopediya v 6 t. – t. 4. Pp. 249–250. Kazan', Institut tatarskoi ehntsiklopedii AN RT. (In Russian)
6. Tazeeva, K. S. (1994). *Mansur Muzafarov: kompozitora* [Mansur Muzafarov: A Composer]. 152 p. Kazan', Tatknigoizdat. (In Tatar)
7. Asaf'yev, B. V. (1947). *Glinka* (1804-1857) [Glinka]. Analiz tvorchestva. Akad. B. Asaf'yev (Igor' Glebov). 308 p. Moscow, izd-vo i tipolitogr. Muzgiza (tip. izd-va “Mosk. Rabochiy”). (In Russian)
8. Sokhor, A. (1962). *O vzaimodeystvii vokal'nykh zhanrov v tvorchestve sovetskikh kompozitorov* [On Interactions of Vocal Genres in the Work of Soviet Composers]. Voprosy teorii i estetiki muzyki. Pp. 186–218. Leningrad, Muzgiz. (In Russian)
9. Khabutdinova, M. M. (2022). *“Miras – 2022”* [“Miras – 2022”]. Zvezda Povolzh'ya. No. 7 (1069), 26 fevralya – 4 marta, pp.1,4. (In Russian)

---

# КОМПОЗИТОР МАНСУР МОЗАФФАРОВ: ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ СТИЛЬЛЕ ИҖАТ

**Клара Сабир кызы Таҗиева,**
mileuscha@ mail.ru.

Татар композиторларының өлкән буын вәкиле Мансур Мозаффаров иҗаты – татар профессиональ музыкасында аның туган вакытыннан алып, сәнгатьчә җитлегү чорын эченә алган чордагы бер искиткеч гүзәл күренеш ([1], [2], [3], [4], [5], [6]). Композиторның дөньяга карашы татар халкының Беренче рус революциясе елларында милли үзаңы көчле күтәрелеш кичергән чорда формалашты. Мәшһүр татар шагыйрәсенең улы, үсмер вакытыннан ук татар милли әдәбияты һәм сәнгатенең күренекле эшлеклеләре Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Салих Сәйдәшевлар даирәсендә кайнашып үсә. Үзенең бөтен гомерен музыкага, иҗатка һәм яшь татар музыкантларын тәрбияләүгә багышлый.

Үзенең иҗат юлында М. Ә. Мозаффаров аңлы рәвештә реализм принципларына таяна, яшь милли сәнгатьтә халыкчанлык, интернационализм һәм демократизм, тормыш хакыйкатенә тугрылык һәм тирәнтен кешелеклелек рухын урнаштыруга булышлык итә.

Башка композиторларныкы кебек үк, Мозаффаровның да үз образлары даирәсе бар. Күпчелек очракта ул тирә-як тормышка гашыйк, дөньяның матурлыгына дан җырлаучы лирик герой. Еш кына герой сыйфатында шагыйрь образы күз алдына баса, һәм ул тарихи шәхес буларак кына сурәтләнми, ә сәнгать символы, халык фикерен, намусын гәүдәләндерүче аваз булып яңгырый. Бу җәһәттән Мозаффаров герое татар музыкасында шагыйрь образын («Габдулла Тукай истәлегенә» симфоник поэмасы), аның тарихта уйнаган ролен трактовкалауның беренче үрнәге булды. («Габдулла Тукай истәлегенә», «Мулланур Вахитов истәлегенә» симфоник поэмалары).

Мозаффаровка тормышта яктылыкка, идеалга ирешү омтылышы хас. Аңа инкарь итү түгел, ә раслау якын, эчке каршылыкларны тасвирлау, ачудан бигрәк максатчан, яхшылыкка һәм гаделлеккә юл таба белгән кешеләрне тасвирлау мөһим. Бу яктан ул рус классиклары Глинка, Бородин, Римский-Корсаковка якын тора.

Мозаффаров талантының үзенчәлеге шунда ки, ул үз халкының сәнгатьчә фикерләвенең лирик якларын ачарга омтыла. Бу композиторның үзенең эмоциональ-психологик табигате белән, аның чиктән тыш тыйнак, гаҗәеп кешелекле, үз халкын яраткан, шулай ук композитор буларак, бай аһәңгә ия булган му-

зыкаль сәләте һәм кешелекнең гадәттән тыш күптөрле эмоцияләрен музыка чаралары аша бирә белүе белән бәйләнгән.

Шунысы игътибарга лаек: башка татар композиторлары арасында Мозаффаровны аерып торган лирик юнәлеш аның иҗатының буеннан-буена озата барды, ул баетылу, аңа эпик һәм драматик хәрәкәтчән сыйфатлар үтеп керү, әсәрләре тематикасында гомумиләштерү-фәлсәфи башлангычларның көчәюе ягына үзгәрешләр кичерде.

Мозаффаровның иҗат мирасы жанрлар төрлелеге белән аерылып тора. Ул татар профессиональ музыкасын жанр ягыннан баету өчен көчле этәргеч бирде, ул күп жанрларга Татарстанда беренче булып мөрәҗәгать итте.

Композиторның симфоник музыка өлкәсендәге хезмәтләре аеруча зур әһәмияткә ия, бигрәк тә программалы поэма жанрында. Биредә дә ул татар мәдәниятенең алдынгы фикере тарихында мөһим темага – татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай темасына алынып, зур уңыш казанды («Габдулла Тукай истәлегенә» симфоник поэмасы). Ялкынлы революционер Мулланур Вахитов темасына алынуы да композитор игътибарының киң халык массаларын кызыксындырган вакыйгаларга юнәлгән булуы хакында сөйли («Мулланур Вахитов истәлегенә» симфоник поэмасы). Мансур Мозаффаров талантының шушы иң югары ноктасындагы әсәрләрдә зур композиторның югары профессиональ осталыгы чагылды. Ул татар музыкасында программалы лирик-драматик симфоник поэмаларның чишмә башы булды.

Мансур Мозаффаров милли симфониягә нигез салучыларның берсе булды. Аның «Татар халык көйләре темаларына увертюра» (1932), «Симфония ми-минор» (1944), «Халык көйләре темаларына увертюра» (1951), «Өч кисәкле симфониетта» (1954) кебек әсәрләре бар. Ул бу өлкәдә классик биеклекләргә ирешмәсә дә, аның симфониясе татар әсәрләреннән беренче буларак, киң аудиториягә җитеп, бу жанрны үзләштереп килүче яшь композиторларга – А. Ключаревка, А. Вәлиуллинга, А. Монасыйповка зур ярдәм итте («Татар халык көйләре темаларына увертюра» (1932), «Симфония-ми минор» (1944), «Халык көйләре темаларына увертюра» (1951), «Өч кисәкле симфониетта» (1954)).

М.Мозаффаров шулай ук милли композиторлар арасында скрипка концертлары жанрын үзләштерүдә дә беренче булды. Ул бу жанрда мелодик матурлыгы, милли стихиясе, бетмәс-төкәнмәс лирик агылышы буенча гаҗәеп гүзәл «Скрипка һәм оркестр өчен концерт № 1» (1959), «Скрипка һәм оркестр өчен концерт № 2» (1962) кебек әсәрләр иҗат итә алды.

Мансур Мозаффаровның симфоник стиле формалашуның беренче этапларында ук инде аның иң мөһим үзенчәлеге – инструменталь музыканың халык җыр иҗаты белән аерылгысыз бәйлелеге ачык билгеләнә. Татар җырларын турыдан-туры цитаталау, аның аерым мотивларын һәм бормаларын кулланудан башлап, Мозаффаров үзенең лад табигате, интонацион закончалыклары, сыгылмалы пластикасы буенча халык музыкасына аһәңдәш оригиналь темалар таба.

Еш кына бер үк әсәрдә халык аһәңнәренең һәм композитор хыялында туган көйләрнең иркле рәвештә бергә яшәүләре күзәтелә. Җыр көйләре бер интонациянең төрлечә вариацияләнүеннән формалашкан кебек, Мозаффаровның да симфоник темалары берберсенә охшаш мелодик буыннардан акрынлап үсеп чыга. Эшкәртмә бүлекләрендә теманың үсеше шулай ук дулкынсыман хәрәкәт белән билгеләнә. Халык җыр теле элементларын яңа сыйфатка кирәклек итеп гомумиләштерү осталыгына композитор аның өлгергән әсәрләрендә генә ирешә. Аның иң яхшы поэмалары әнә шул хакта сөйли.

Татар симфоник музыкасы формалашуга башка халыкларның, аерым алганда, рус мәдәниятенең йогынтысы көчле булды. Яңа аһәңнәр һәм ритмнарны, кызыклы драматик алымнарны милли стихия белән оста аралаштыру Мозаффаров иҗатына яңа саф агымнар кертеп җибәрде.

Мозаффаров симфоник әсәрләренең башка жанрлар белән, аерым алганда, опера белән бәйләнеше булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Көйләрне эшкәртү осталыгы операдагы речитативлар өстендә җентекләп эшләү дәверендә килә. Нәкъ менә опера өстендә эшләү инструменталь тематизмның җете образлылыгына ирешүдә ярдәм итте. Мозаффаров иҗатында инструменталь тематизмны җыр-вокал юнәлешенә капма-каршы кую да опера драматургиясеннән килә.

Җыр һәм инструменталь жанрларның даими үзара бәйләнеше милли һәм классик культураларны аралаштыру юлы белән Мансур Мозаффаров татар музыкасы өчен яңа булган симфо-

ник сәнгать тудыру эшендә сизелерлек уңышларга иреште.

Опера жанрына мөрәҗәгать итеп, Мансур Мозаффаров халыкчан, халыкның киң катламы яраткан, аңа якын булган сюжетлар тапты. Аларның эчтәлеген ачар өчен композитор популяр халык җырларының интонацион байлыгын файдалана. Бу бигрәк тә аның беренче операсы «Галиябану»да ачык чагыла. Опера сәнгате туып кына килгән милли республикаларда котылгысыз рәвештә халык көйләрен циталау принцибын тарихи позицияләрдән торып кына карарга мөмкин. Билгеле бер этапта бу алым, һичшиксез, яшәргә хокуклы иде. Ул гына да түгел, халыкның киң катламын аның өчен яңа булган опера мәдәниятенә тартуда бу зарури да иде. Бу тарихи процесс опера сәнгате совет чорында гына барлыкка килгән Татарстанда да күзәтелде. Икенче операсы булган «Зөлхәбирә»дә М. Мозаффаров фольклорны турыдан-туры файдалану принцибыннан баш тарта, үз халкының музыкаль теле элементларын гомумиләштерүдә яңа биеклекләргә күтәрелә. Бу операның нигезендә «Галиябану»дагы кебек җыр түгел, ә бәет ята. Бәет – татар фольклорының аерым бер жанры, ул сюжет сызыгының драматик үсешен күз алдында тота. Бу табигый ки, башка тасвирлау чараларын таләп итә. Бәет жанрының музыкаль-шигъри чараларын опера спецификасы белән берләштерү Мозаффаров иҗатында яңа бер кызык-лы сәхифә булды. Милли үзенчәлекне яңа сыйфатка ия булырлык дәрәҗәгә, чын мәгънәсендә театраль-музыкаль лексикага әверелдерү – бу инде милли опера формалары үсешенең яңа этабы. Бу Мансур Мозаффаров иҗатында раслау таба.

Мозаффаровның музыкаль-театраль әсәрләре татар операсының жанрлар палитрасын киңәйттеләр. Татар музыкасында лирик-көнкүреш операсы барлыкка килү аның исеме белән бәйләнгән.

Мозаффаров исеме шулай ук татар җыр сәнгате үсеше тарихыннан да аерылгысыз. Салих Сәйдәшев, Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллиннар белән бергә ул яңа татар совет җырларын тудыруны башлап җибәрүчеләрдән булды. Республиканың башка күп композиторлары кебек, ул да шул заманның барлык әһәмиятле вакыйгаларына мөнәсәбәтен иҗаты аша белдерде. Мозаффаров музыкасының эмоциональ дөньясы безнең замандашыбызның Ватанга, халыкка булган тугры мәхәббәтен, халыкның бөек эшләренә горурлык тойгыларын чагылдырды. Мозаффаров җырларында иркенлек, сөйләмдәге ихласлык, эчкерсезлек, ачыктан-ачык эмоциональлек үзенә җәлеп итә. Аның иң яхшы җырларындагы һәр гыйбарә, һәр аһәң җырлаучының эчке кичерешләре кебек кабул ителә һәм гаҗәеп саф, кабатланмас матур яңгырый.

Композитор җырларының тематик диапазоны гаять киң булса да (Туган ил-Ватан, замандашлар, саф мәхәббәт турындагы һәм күңелле шаян җырлар), анда төп урынны лирика алып тора, хәтта лирик булмаган темаларны да ул лирик яктан ачарга тырыша. Моның сәбәбе – Мозаффаров үзе лирик табигатьле композитор. Ул гомуми булган нәрсәләрне дә эмоциональ-шәхси күзлектән карап ача, аны, гадәттә, халык массаларына якын һәм аңлаешлы тойгылар һәм кичерешләр кызыксындыра.

Еш кына композиторның интонация үзгәрешләре нәкъ менә җыр жанрында ачык чагыла. Мәсәлән, иҗатының һәр чорында аның үз буяулары, үз тасвирлау чаралары бар: 30 нчы еллар җырлары өчен якты һәм шатлыклы көр күңеллелек, халык чыганакларына якынлык хас. Сугыштан соңгы әсәрләрендә гражданлык лирикасына тартылу ачык чагыла, ә 50 нче, 60 нчы еллар башындагы әсәрләре лирик-фәлсәфи эчтәлекле, алар индивидуальләшкән стиль көчәю, яңа интонацияләр мохите эзләү белән аерылып тора.

Җырда көй (мелодия) төп тасвирлау чарасы булып тора. Нәкъ менә көйләренең җетелеге, образлы төгәллеге Мозаффаров җырларының популярлашуына ярдәм итте. Аның көйләре халык көйләренә якын, ләкин аларда «башкалардан» күчерү, ягъни «цитаталап кабатлау»ны таба алмыйсың, халык җыр аһәңнәре аларда шулкадәр нечкә яңара, алар аның үз көйләре булып яңгырыйлар. Б. В. Асафьевның Глинка иҗаты турында әйткән сүзләрен искә төшерик: «Халык музыкаль теле элементларын үзеңә күчерү түгел, бәлки, бу тел элементларын гомумиләштереп, музыкаль аңның яңа баскычына күтәрү тәҗрибәсе мөһим», – ди ул [7]. Бу сүзләрне Мозаффаровка карата да әйтергә мөмкин. Монда композиторның халык вокаль иҗатының үрнәкләрен җыю һәм эшкәртү буенча ару-талуны белмичә эшләве, тырышлыгы, халык мелосының (моңының) рухына һәм асылына тирән үтеп керүе чагылды. Әмма Мозаффаровның үз иҗат йөзе, үз үзенчәлекләре: эмоциональ яктан тыгызлыгы, уйлануларының тирәнлеге һәм тойгыларның тыелгысыз ялкыны ташып торган көйләре ае-

руча кыйммәтле. Аның иҗат җимешләренең иң яхшы үрнәкләрендә көй зур диапазонны колачлап, иркен һәм киң булып агыла, үсеш юнәлеше түгәрәкләнеп, дулкын-дулкын булып сузыла. Аларда башлангыч киң аһәңлелекнең әһәмияте зур (бу киңлеккә еш кына секста, кайчак септима интервалы аша, күп очракта икеләтә сикереш исәбенә ирешелә). Ә хәрәкәтчән көйләрдә мондый башлангыч үзенчәлекле аһәң таррак интерваллар — терция, кварта белән бәйләнә. (Мәсәлән, «Хат ташучы җыры», «Кулъяулык».) Мозаффаров җырларының көй сурәтләре никадәр киң колачлы, иркен булса да, алар һәрвакыт халык көйләренә хас булган пентатоникага таяна. Нәкъ менә шуңа күрә дә бөтен интонацион яңалыгына, катлаулылыгына, кабатланмас булуына карамастан, алар җиңел үзләштереләләр, тиз отып алыналар.

Мозаффаров мелодикасының интонацион үсешендә тагы бер үзенчәлек – татар фольклорына да хас булган кушылма өннәр (төп тоннар күршедәге авазлар белән уратып алыналар, үзенә күрә «юлдашлык» хасил итәләр). Мозаффаровта моннан тыш тагын якында яткан (секунда, терция) интерваллар белән бергә кушылу нәтиҗәсендә туган – (кварта, квинта, секста) тоннар да очрый («Тын бакчада», «Шәһәр кызы», «Менәргә иде Урал тауларына»). Мондый алым композиторның лирик көйләренә аеруча тулылык, тотрыклылык, объективлык бирәләр. Героик-тантаналы җырларда исә бер юнәлештә акрынлап киеренкеләнә барган максатка омтылучанлык («Туган ил» җыры) хас.

Мансур Мозаффаров татар масса җырлары үсешенә дә зур өлеш кертте. Ул вокаль әсәрләрне яңа образлар, яңа жанр төрләре белән баетты. Шунысы мәгълүм: 60 нчы еллар вокаль музыкасында музыка белгече А.Сохор сүзләре белән әйтсәк, «төрле жанрларның якынлашуы, бер-берсенә актив үтеп керү процессы бара. Аларның чикләре күчерелә. Яңа жанр төрләрен эзләү бара» [8]. Һәм Мансур Мозаффаровның озак еллар буе синтезланган кушылма җыр-романс жанрын эзләп табуы — аның үз иҗатында заман таләпләре белән бер аяктан атлап баруы турында сөйли торган факт.

Профессиональ осталыкның һәм идея-эстетик өлгергәнлекнең югары дәрәҗәсенә ирешү өчен аңа үз халкының музыкаль фольклоры өстендә җентекләп эшләү ярдәм итте. Аның стиленең төп сыйфаты итеп милли үзенчәлекне әйтү кирәктер. Мозаффаров татар милли музыкасы тарихына милли музыкаль телгә нигез салучыларның берсе булып кереп калды. Композиторның стиле формалашуда, аның иҗатында теге яки бу сәнгать алымнарының өстенлек алуына нәкъ менә халык җырлары йогынты ясады. Мозаффаровның иҗат юлы халык җыр иҗат җәүһәрләрен тирәнтен үзләштерүдән башланды. Мансур Мозаффаровның йөзләрчә татар халык җырларын иҗади эшкәртүе композиторның татар музыкасының асыл милли сыйфатларын армый-талмый эзләве турында сөйлиләр. Ул халык әсәрләрен сәнгатьле эшкәртү жанрына мөстәкыйль иҗат итеп караучыларның берсе булды. Композиторның бу өлкәдәге туктаусыз эшләве бай нәтиҗәләргә китерде, аның музыкаль теленең халыкчанлыгына һәм аңлаешлы булуына, татар музыкаль мәдәниятенең кыйммәтле элементларын гомумиләштереп, үз мөстәкыйль стилен ачыкларга ярдәм итте. Мансур Мозаффаровның татар музыкаль фольклорын җыю һәм нәшер итүдә дә хезмәтләре гаять зур.

Фольклор белән элемтәсе барыннан да элек аның әсәрләренең мелодикасында чагыла. Аның кайбер әсәрләрендә тематик материал буларак, халык көйләре файдаланылган (мәсәлән, скрипка концертларының салмак кисәкләре, симфоник поэмаларының темалары шундый). Аның үз темалары да халыкныкына якын.

Материалны үстерү ысуллары арасында халык иҗатыннан килгәннәре аеруча зур әһәмияткә ия. Әмма бу ысулны турыдан-туры файдалану түгел, ә ныклап уйлап, «шәхси мин»ең, ягъни күңелең аша уздырып, иҗади файдалану. Моңа мисал булып, инструменталь темалар хезмәт итә ала. Мозаффаров әнә шулай эшли. Шул ук вакытта композитор классик музыкага хас алымнарга еш мөрәҗәгать итә, даими рәвештә полифоник ысуллардан файдалана, музыкаль тукыманы симфонияләштерә һәм шуның белән татар музыкасын сыйфат ягыннан яңа югарырак яссылыкка күтәрә.

Мансур Мозаффаров милли музыка телен үстерү өчен бик күп эшләде. Ул үзенең хосусый, үзенчәлекле стилен булдырды, бу исә үз чиратында бөтен милли музыканы баетуга ярдәм итте. Аның гармония, фактура өлкәсендәге табышлары бәяләп бетергесез. Аның тарафыннан гармонияне пентатоника белән берләштерү бурычлары уңышлы чишелеш тапты, симфониягә бирелешле тематизм табылды.

Мансур Мозаффаровның Татарстан профессиональ музыкасының үсеш процессында тот-

кан урынын билгеләү өчен, аның белән янәшәдә торып иҗат иткән зур осталарның да исемнәрен әйтеп китәргә кирәк. Барыннан да элек аның дусты һәм хезмәттәше Салих Сәйдәшев, аннан соң композиторлар Александр Ключарев, Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи. Иҗатның нигезен тәшкил иткән принциплар – халык иҗаты белән бәйләнеш, зур темаларга игътибар бирү – алар өчен уртак. Әмма аларның һәркайсы тирәнтен үзенчәлекле, конкрет чагылышта индивидуаль. Алар барысы да татар музыкаль сәнгатенең үсеш юлына зур йогынты ясаган осталар.

Мозаффаровтан яшьрәк буын композиторлары аның әсәрләрен игътибар белән өйрәнәләр һәм үз иҗатларында аның традицияләрен дәвам иттерәләр. Бу, нигездә, музыканың лирик сферасына кагылганда, ачык чагыла. Мозаффаровныкы кебек үк, аларның да лирик образлары бик сурәтле, мелодик үсешенең табигыйлеге, музыкаль фикернең иркен агышы белән игътибарны җәлеп итә. Лирик башлангыч А. Монасыйпов һәм Р. Еникеев иҗатында, әмма инде яңа этапта, бөтенләй башка шартларда чагылыш тапты. Мозаффаров җырлары традициясе йогынтысы Р. Еникеев, А. Монасыйпов, И. Якупов, Р. Яхин иҗатларында индивидуаль башлангычның көчәюе, аның беренче планга чыгарылуы рәвешендә чагылды. М.Яруллинны, Р. Биляловны иҗади эшкәртү жанры кызыксындыра. Р.Билялов шуның өстенә, Мозаффаров кебек үк, халык җыр материалына таянып, бөтен бер инструменталь цикллар да төзеде. Ф. Әхмәтов һәм А. Монасыйповның симфоник поэмалары, үз вакытында Мозаффаров күп көч куйган жанрны баеттылар. Аларның бер кисәкле программалы әсәрләре безнең замандашлар – шагыйрь Муса Җәлилгә һәм композитор Фәрит Яруллинга багышланды. Мозаффаровның лирик-драматик симфонизмына якынлык татар композиторларының камера әсәрләре өлкәсендә дә, аерым алганда, Ренат Еникеевның ялкынлы революционер Хөсәен Ямашев истәлегенә багышланган икенче сонатасында күзәтелә. Асылда, ул фортепиано өчен поэма булып тора. Мозаффаровның опера иҗатыннан соң лирик-драматик образлар белән кызыксыну Х. Вәлиуллин, Р. Гобәйдуллин, Б. Мөлеков әсәрләрендә күзгә ташлана.

2022 елның 9 февралендә Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында «Мирас» татар музыкасы фестивален ачу тантанасы булды. Беренче кичәнең программасы Мансур Мозаффаровның тууына 120 ел тулуга багышланган иде. Бу кичәдә беренче тапкыр 1938 елда, композитор иҗатының башлангыч чорында иҗат ителгән татар темаларына увертюра башкарылды. Аның нигезен ике татар халык җыры: «Җизнәкәй» һәм «Кәккүк» җырлары тәшкил итә. Композитор Ильяс Камал архивта сакланып калган кульъязмалар буенча яңадан торгызылган әсәрне беренче мәртәбә башкарды. Татарстан Дәүләт академия симфоник оркестры башкаруында шулай ук «Ре-мажор темасына увертюра» (1932), Мулланур Вахитов истәлегенә язылган симфоник поэма яңгырады. «Галиябану» операсыннан Кереш, Галиябану ариясе, Бию, Бәдри җыры, Дуэт кебек өзекләр тамашачыларда аерым кызыксыну уятты. Солистлар булып, Илүсә Хуҗина һәм Руслан Закиров чыгыш ясады. Ильяс Камал виолончельда оркестрга кушылып (А. Луппов оркестровкасында), «Көй» әсәрен башкарды. Халык композиторның җыр иҗаты белән хозурланды. И.Хуҗина башкаруында Муса Җәлил шигыренә иҗат ителгән «Җиләк җыйганда» җыры яңгырады. Җырчы Алмас Хөсәенов Мөнир Мазунов шигырьләренә язылган «Туган як» җырын башкарды. Көйнең искиткеч матурлыгы һәм гармониясе, нечкә оркестр интерпретациясе белән сугарылган булуы талантлы тенор А. Хөсәеновны тамашачының көчле алкышларына күмде. Концерт Казан консерваториясенең скрипка кафедрасы укытучысы, Бөтенроссия һәм Халыкара конкурслар лауреаты Динә Хисанбеева чыгышы белән тәмамланды [9].

Барлык әйтелгәннәр Мансур Мозаффаровның татар профессиональ музыка сәнгатенең барлыкка килүе һәм үсешендә тоткан роле гаять зур икәненә ышанычлы дәлил булып тора.

**Әдәбият**

1. Башка берни дә кирәкми : ф.-попул.очерк, хатирәләр, фоторәс. / төз. К. С. Таҗиева; Татар. Г. Н. Әхмәтҗанов тәрҗ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 192 б.

2. *Дулат-Алеев В.* Мансур Музафаров // В. Дулат-Алеев Татарская музыкальная литература. Казань, 2007. С. 167–180.

3. *Исхакова-Вамба Р. А.* М. А. Музафаров // Р. А. Исхакова-Вамба Фольклор и композитор (на материале татарской музыки): очерки. Казань: Школа, 2006. С. 44–58.

4. *Нигмедзянов М.* Музафаров Мансур // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. Казань, 1986. С. 106–113.

5. Салитова Ф. Ш. Музафаров Мансур Ахметович // Татарская энциклопедия в 6 т. Т. 4. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2008. С. 249–250.

6. *Тазеева К. С.* Мансур Музафаров: композитора. Казань: Таткнигоиздат, 1994. 152 с.

7. *Асафьев Б. В.* Глинка. (1804–1857) / акад. Б. Асафьев (Игорь Глебов). М.: изд-во и типолитогр. Музгиза, 1947 (тип. изд-ва «Моск. рабочий»). 308 с.

8. *Сохор А.* О взаимодействии вокальных жанров в творчестве советских композиторов // Вопросы теории и эстетики музыки. Л.: Музгиз, 1962. С. 186–218

9. *Хабутдинова М. М.* «Мирас – 2022» // Звезда Поволжья. 2022. № 7 (1069). 26 февраля – 4 марта. С. 1, 4.